**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Азнакай
муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района,
423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
От «01» ноябрь 2024 ел № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024елның 15 нояберендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының билгеләргә:

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл төзү)

« РИЗА»　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәндәй авылы, Ялантау ур., 36б йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык:　　　　　　　　　　Н. Ә.Фәтхетдинов.